Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче
Мерәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел

№ 04

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Мерәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Мерәс авылының урам спорт мәйданчыгын сатып алу)».

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылында гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Мерәс авылының урам спорт мәйданчыгын сатып алу)».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина